УДК 372.881.512.145

*Э.Г. Багирова*

# БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Обучение детей татарскому языку в детском саду – одна из самых сложных методических задач. Для того чтобы обучение принесло положительный результат, нужно правильно построить процесс обучения, при котором сохраняется самобытность и специфика дошкольного детства, нормальный ход развития детей. Раньше в преподавании языков доминировали академичность, теория, но сейчас идет обращение к практике ориентированности, мультимедийности, обучения с помощью игр, сказок, мультфильмов.

**Ключевые слова:** татарский язык, обучение с помощью игр, теория, методика.

Милли мәдәниятне, халыкның гасырлар дәвамында формалашкан рухи байлыгын бары шул халыкның теле ярдәмендә генә үзләштерергә мөмкин. Туган телне балаларга кече яшьтән үк өйрәтеп кенә, аларда телгә һәм шул тел аша халыкның мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләргә мөмкин. Бу учреждениеләрдә балаларга татар телен өйрәтү катлаулы методик бурычлардан санала. Балалар бакчаларында тел өйрәтү методлары һәрвакыт үсеш-үзгәрештә булып, соңгы елларда балалар бакчаларында татар теле укытуда да яңа методларга ныграк игътибар юнәлтелә. Хәзерге вакытта мәктәпкәчә яшьтәге балаларга татар теле укытуның методлары бу процессны укытучы өчен дә, бала өчен дә кызыклырак итүгә юнәлтелгән. Белем бирүдә, академиклыкка, теорияне өйрәтүгә басым ясау урынына, уеннар, халык иҗаты, мультфильмнар ярдәмендә, мультимедия, практика аша тел өйрәтү алгы планга чыга. Ягъни балалар телне уен аша, уйнап өйрәнәләр. Уйнау – бала өчен табигый халәт. Шуңа күрә бала белән аралашканда үзара аңлашуга да уен аша ирешү җиңелрәк. Шул ук вакытта шуны да истән чыгарырга ярамый, теләсә кайсы стресс халәте баланың уйнарга булган теләген һәм, нәтиҗә буларак, чит телне өйрәнергә булган омтылышын юкка чыгара. Димәк укытучы дәрестә, уен атмосферасы тудыруга һәм уен ярдәмендә телне өйрәтүгә ирешү өчен, уңай эмоцияләргә нигезләнгән фон сакларга кирәклеген истә тотарга тиеш була. Шуңа күрә балалар дәрестә үзләрен иркен тотарга, йончымаска һәм кызыксынуларын сакларга тиеш. Дәрес шартлары никадәр комфортлы булса, чит телне өйрәнү процессы шулкадәр интенсив бара. Балаларга уен аша телне өйрәтү укытучыдан югары профессионализм, күп төрле сәләткә ия булуны һәм зур тырышлык таләп итә. Укыту процессы уңай нәтиҗәләр бирсен өчен, мәктәптәгечә, балаларның яшь үзенчәлеге һәрвакыт искә

алынырга тиеш. Бу очракта, беренче чиратта, укыту процессы бала өчен кызыклы һәм файдалы булырга, тел өйрәтү мәктәп дәресенә әйләнеп калмаска тиеш.

Балалар бакчаларында тел дәресләрендә дидактик уеннар куллану бик отышлы. Ул балага тел өйрәтүнең бер формасы да, шул ук вакытта баланы төп шөгыленнән – уеннан да аермый. Дидактик уеннарның асылы, аларның исеменнән үк аңлашылаганча, өлкәннәр тарафыннан өйрәтү һәм тәрбия максатыннан уйлап чыгарылганнар. Әмма балаларга уенның тәрбияви һәм белем бирү функциясе алга чыкмый, тәрбия һәм белем бирү уен шартлары, кагыйдәләре, хәрәкәтләре аша тормышка ашырыла.

Шәхси тәҗрибәмнән чыгып, балалар бакчасында балаларга татар теле өйрәтүнең кайбер мәсьәләләре белән таныштырып үтәргә булдым. Озак еллар мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә эшләгәннән соң, балаларга белем бирү процессында нәкъ дидактик уеннарның әһәмияте зур булуны аңлыйсың. Дидактик уеннар – педагогикада балаларны укыту һәм тәрбияләү максаты белән махсус төзелгән уеннар ул. Бу уеннар аерым бер мәсьәләне хәл итүгә юнәлтелә, шул ук вакытта аларда уен процессының баланы тәрбияләү һәм белем алу күнекмәләрен үстерү эшчәнлеге дә чагыла. Дидактик уеннарның мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү эшчәнлеген активлаштырудагы, мөстәкыйль танып-белү эшчәнлеген формалаштырудагы әһәмияте дә зур. Балалар бакчаларында укыту процессы нәкъ дидактик уеннарга нигезләнеп оештырыла. Балаларның өйрәнелгән материалны ныгыту процессында да дидактик уеннар ярдәмгә килә.

Дәрестә дидактик уеннар кулланганда, алар түбәндәге максатларга җавап бирергә тиеш:

1. Программада каралган материалны яхшырак үзләштерергә ярдәм итү.

2. Татар теленең лексикасын (ягъни аерым тематик төркемнәргә караган сүзләрне) үзләштерергә ярдәм итү.

3. Сөйләм материалын уен формасында ныгыту, татар телен өйрәнүгә кызыксынуны арттыру.

Укыту эшчәнлегендә файдаланылган теләсә кайсы уен методикасының нигезе түбәндәге принципларга нигезләнә: дидактик материалның актуаль булуы һәм дөрес сайлануы балаларга мәсьәләләрне уен дип кабул итәргә булыша, дөрес һәм иң отышлы җавап табарга омтылыш тудыра. Дидактик уеннарның тагын бер әһәмияте шунда, бу уеннар аша балалар бердәм группа булып зуррак һәм катлаулырак мәсьәләләрне хәл итәргә сәләтле коллективта эшләргә өйрәнә. Ярышып эшләү балаларда эшне тизрәк һәм башкаларга караганда нәтиҗәлерәк тәмамлауга этәрә, бу, бер яктан, билгеле бер мәсьәләне чишүгә бирелгән вакытны кыскартса, икенче яктан, тел өйрәнүдә дә реаль нәтиҗәләр бирә.

Тел өйрәтү дәресләрендә кулланылган дидактик уеннар түбәндәге таләпләрне истә тотып сайланырга тиеш. Һәр дидактик уен бала өчен яңалык алып килергә тиеш. Анда узган дәресләрдә

очрамаган яңа элементлар кертелү зарур. Балалар уйнарга теләмәгән уенны мәҗбүриләп бирү тискәре эффект бирә ала, һәр бала үз теләге белән уенга керергә тиеш. Балаларның үзләренә ошамаган уеннан баш тартырга, башка уен сайларга мөмкинлеге булырга тиеш. Уен – ул дәрес кенә түгел. Балаларны яңа темага алып керә торган, ярыш элементлары кергән, экият дөньясы белән таныштырган уен алымнары, беренчедән, укытучының методик байлыгы һәм сәләте булса, икенче яктан, балаларның тәэсиргә бай уртак эш процессы да. Укытучының эмоциональ халәте дә ул оештырган эшчәнлеккә туры килергә тиеш. Башка методик чаралардан аермалы буларак, дидактик уенның тиешле нәтиҗәләр бирүе оештыручының халәтенә дә бәйле. Укытучы уенны оештыра белергә генә түгел, балалар белән үзе дә уйный белергә тиеш.

Дидактик уеннар барышында баланың үз-үзен тотышы аша, аны яхшырак өйрәнергә, проблемаларын ачыкларга мөмкин. Уйнаганда баланың уңай һәм тискәре сыйфатлары ачыла. Уен кагыйдәләрен яки уен атмосферасын бозган бала белән йомшак кына сөйләшү, аңлашу да уңай нәтиҗәләр бирә. Әмма балага җәза бирелергә тиеш түгел.

Балаларга бакча яшеннән туган телне өйрәтү – хәзерге вакытта дөнья күләмендә актуаль проблемаларның берсе. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында да балалар бакчаларында татар телен өйрәтү актуаль мәсьәлә. Туган телне, татар телен аралашу чарасы буларак яхшы өйрәнү, киләчәктә яхшы белем алу өчен генә түгел, баланың интеллектуаль һәм әхлакый җитлегүе өчен дә мөһим.

Телне максатчан рәвештә өйрәнүнең зарурияте Л.С. Выготский, А.М. Шахнарович, А.А. Леонтьев, Г.Ш. Әсәдуллин, Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова һәм башка галимнәрнең фәнни хезмәтләрендә чагыла. Галимнәр тел өйрәнү өчен нәкъ мәктәпкәчә яшьнең сенситив чор булуын, бу яшьтә баланың телгә караган информацияне кабул итәргә һәм ныклап хәтерендә калдырырга эмоциональ яктан әзер булуын ассызыклыйлар. Теләсә кайсы телнең төп функциясе аралашу чарасы булган кебек, балалар бакчасында тел өйрәтүнең төп максаты да – коммуникация, ягъни шул телдә сөйләшергә өйрәтү.

Баланы сорауларга җавап бирергә генә түгел, үзен дә сораулар бирергә, сөйләшергә, әңгәмәдә катнашырга, яшьтәшләре белән аралашырга өйрәтү мөһим.

Шуңа күрә без татар телен өйрәтү процессын, бу эшкә ата-аналарны, балалар бакчасы тәрбиячеләрен дә җәлеп итеп, өзлексез процесс итәргә омтылабыз. Балаларга татар теле өйрәтүдә балалар бакчасы тәрбиячеләре, педагоглар да һәрдаим ярдәмгә килә. Аларның татар телен өйрәнүенең әһәмиятен аңлап, тел өйрәтү процессында булышлык итүе укытучы өчен дә зур стимул булып тора. Чөнки бары тел өйрәтү процессы бер укытучының тырышлыгы белән генә тиешле нәтиҗәләрне бирә алмый.

Безнең мәктәпкәчә яшьтәге учреждениедә «Без татарча сөй-

ләшәбез» дигән укыту-методик комплексын тормышка ашыру (УМК «Говорим по – татарски») өч юнәлештә башкарыла:

1. Балаларны дәүләтебезнең ике телендә укыту (рус һәм татар телләре).

2. Рус теле тәрбиячеләренә татар телен өйрәтү.

3. Балалар бакчасында балалар һәм тәрбиячеләр өчен татар телендә аралаша торган милли мохит булдыру.

Безнең балалар бакчасына балаларга дәүләтебезнең ике телендә дә белем һәм тәрбия бирә торган 15 төркемдә 380 бала йөри. Бу балалар өчен атнага өч тапкыр татар теле дәресләре уздырыла. Бер дәрескә балаларның яшеннән чыгып 20–30 минут вакыт бүленә.

Балалар татар теле дәресләренә теләп йөриләр. Дәресләрдә телне уен формасында өйрәнәләр, татар халкының тарихы, мәдәнияте белән танышалар, татар телендә мультфильмнар карыйлар. Каралган мультфильмнардан соң, шул сюжетка ясалган рәсем күргәзмәләрендә дә балалар бик теләп катнаша. Ул рәсемнәрдән ата-аналар өчен күргәзмәләр дә оештырабыз.

Татар теле дәресләре махсус җиһазландырылган кабинетта уздырыла. Кабинетта балаларны Татарстан Республикасы халыкларының тормышы, этнографиясе, мәдәнияте, көнкүреше белән таныштыру өчен материал тупланган. Татар телен дәресләрендә өйрәнгән уеннарны балалар дәрестә генә түгел, урамда йөргәндә, кичке буш вакытларында да уйныйлар. Татар теле дәресләрендә татар теле өйрәнү дәфтәрләре белән эшлибез. Тел өйрәнү процессын кызыклырак итү максаты белән дәресләрдә аудио- һәм видеоматериаллар, тематик иллюстрацияләр кулланыла. Кабинетта сөйләм эшчәнлеген активлаштыруга юнәлтелгән дидактик уеннар тупланган күргәзмә әсбаплар, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар телендәге матур әдәбият, методик әдәбият саклана.

Һәр яшь категориясе өчен «Татарча сөйләшәбез» дигән махсус почмак әзерләнгән. Биредә балаларның яшь үзенчәлекләре искә алып әзерләнгән, билгеле бер яшьтәге балалар үзләштерергә тиешле тел материаллары, лексик ярдәмлекләр дә урын алган.

Рус телле педагог-тәрбиячеләр «Ана теле» дигән онлайн проектны уңышлы үттеләр. Бу – тәрбиячеләрнең сүзлек запасын баетты, аларга балалар белән уеннар вакытында татар телендә аралашырга этәргеч булды. «Татарча сөйләшәбез» УМКы буенча тәрбиячеләр һәм ата-аналар өчен уздырылган махсус чаралар аларның сүзлек запасын баетырга ярдәм итте. Өлкәннәр балага чит телдә аралашырга өйрәтүдә ярдәмче була, төрле сүз һәм сүзтезмәләрне тиешле урында кулланырга өйрәтә. Шуның нәтиҗәсе буларак, балаларга да татар телендә аралашу өчен, балалар бакчасыннан тыш та сүзлек запасларын баетырга, бакчада өйрәнгән сүзләрне яки сүзтезмәләрне, кирәкле текстларны кабатларга һәм истә калдырырга мөмкинлекләр артты.

Ел дәвамында тәрбиячеләр һәм балалар бакчаларында эшли

торган башка белгечләр өчен «Балаларга дәүләтебезнең ике телен дә өйрәтү буенча авторлык УМКы» дигән юнәлеш буенча консультацияләр уздырылды. Башкарылган эшләр милли тәрбия бирүне, балаларга татар теле өйрәтү буенча эшчәнлекне тагын да югарырак нәтиҗәләргә күтәрергә мөмкинлек бирде. Эш практикасында алда искә алынган УМК буенча эшләү белем бирүнең сыйфатын үстерүгә, балаларда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятуга китерде. Балаларга татар теле укыту буенча үткәрелгән мониторинг аларның татар телен теләп өйрәнүләрен һәм тел буенча белемнәренең югары булуын күрсәтте.

«Татарча өйрәнәбез» дигән УМКы буенча башкарылган эшнең нәтиҗәсе – 2017 елда безнең балалар бакчасы коллективы республика күләмендә уздырылган «Иң яхшы ике телле балалар бакчасы» дигән конкурста катнашып җиңүче булды.

Татар телен киләчәктә өйрәтү буенча түбәндәге перспективалар күзаллана:

педагоглар белән татар телен өйрәнү буенча эшне дәвам итү;

татар теле декадасы оештыру;

татар теле укытучыларының фәнни-гамәли конференциясен оештыру һәм уздыру;

һәр ел була торган музыкаль-әдәби кичәләрне үткәрүне дәвам итү;

Татарстан Республикасы халыкларының этнокультурасы буенча материал туплау;

ике телле балалар өчен татар телендә театр иҗаты түгәрәге оештыру, аның дәвамлы, комплекслы, системалы эшчәнлеген тәэмин итү.

**Әдәбият**

*Бабынина Т.Ф.* В мире национальных культур. Программа приобщения старших дошкольников к национальной культуре народов, населяющих Республику Татарстан. Набережные Челны, 2001.

*Борһанова Р.А.* Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру программасы. Казан, 1994.

*Васильева М.А., Гербова В.В., Комарова Т.С.* Программа воспитания и обучения в детском саду. М.: Мозаика – Синтез, 2005.

*Зарипова З.М.* Программа и методические материалы. Поликультурное воспитание детей старшего дошкольного возраста. Набережные Челны, 2006.

*Зарипова З.М.* Үстерешле уеннар. Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

*Зарипова З.М., Исаева Р.С., Кидрячева Р.Г.* Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү: программа, методик киңәшләр, диагностика. Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.

ФГОС, Игровое обучение детей 5–7 лет. Методические рекомендации / под ред. Н.В. Ивановой. М.: ТЦ Сфера, 2008. 112 с.,

*Крашенинникова Е.* Развитие познавательных способностей дошкольников, ФГОС. М.: Мозаика – Синтез, 2014.

*Шаехова Р.К.* Региональная программа дошкольного образования. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. РИЦ, 2012.

***Багирова Эльвира Гарифулла кызы,***
*Казан шәһәренең 376 номерлы балалар бакчасында*
*татар теле өйрәтү буенча тәрбияче*